МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

07.05.2019 г.Казань № 328

Боерык Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2019 елның 30 маеда 5602 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Инвалидларны эшкә урнаштыруда булышлык күрсәткәндә озата йөрүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 20 ноябрендәге 1064 номерлы боерыгы белән расланган Инвалидларны эшкә урнаштыруда булышлык күрсәткәндә озата йөрүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Инвалидларны эшкә урнаштыруда булышлык күрсәткәндә озата йөрүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү эшен камилләштерү максатларында боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Инвалидларны эшкә урнаштыруда булышлык күрсәткәндә озата йөрүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 20 ноябрендәге 1064 номерлы боерыгы белән расланган Инвалидларны эшкә урнаштыруда булышлык күрсәткәндә озата йөрүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә.Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.05.2019 № 328 боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Инвалидларны эшкә урнаштыруда булышлык күрсәткәндә озата йөрүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 20 ноябрендәге 1064 номерлы боерыгы белән расланган Инвалидларны эшкә урнаштыруда булышлык күрсәткәндә озата йөрүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Инвалидларны эшкә урнаштыруда булышлык күрсәткәндә озата йөрүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 20 ноябрендәге 1064 номерлы боерыгы белән расланган Инвалидларны эшкә урнаштыруда булышлык күрсәткәндә озата йөрүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Регламент):

1 бүлектә:

1.8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.8. Дәүләт хезмәте түбәндәгеләргә нигезләнеп күрсәтелә:

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2002, № 1, 3 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә халык мәшгульлеге турында» 1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 номерлы Россия Федерациясе Законы («Ведомости Съезда народных депутатов РСФСР и Верховного Совета РСФСР», 1991, № 18, 565 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып) (алга таба – Халык мәшгульлеге турында закон);

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1995, № 48, 4563 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә чит ил гражданнарының хокукый хәле турында» 2002 елның 25 июлендәге 115-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2002, № 30, 3032 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, № 31, 3451 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе

Законнар җыентыгы, 2010, № 31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып) (алга таба – № 210-ФЗ федераль закон);

«Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 15, 2036 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып) (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон);

Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы указы (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2012, № 19, 2338 ст.) (алга таба – 601 номерлы указ);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы турында» 2010 елның 8 сентябрендәге 697 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 38, 4823 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Туры килә торган эш эзләү максатларында гражданнарны теркәүгә алу, эшсез гражданнарны теркәүгә алу тәртибе һәм туры килә торган эш эзләүгә карата таләпләр турында» 2012 елның 07 сентябрендәге 891 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2012, № 38, 5103 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып) (алга таба – 2012 елның 7 сентябрендәге 981 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Инвалидларның хокуклары турында конвенция буенча Россия Федерациясе йөкләмәләрен үтәү өчен күрелә торган чаралар турында доклад әзерләү тәртибе турында» 2015 елның 11 июнендәге 585 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2015, № 25, 3666 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Иҗтимагый файдалы хезмәтләр исемлеген һәм аларны күрсәтү сыйфатын бәяләү критерияләрен раслау турында» 2016 елның 27 октябрендәге 1096 номерлы карары (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы, (www.pravo.gov.ru), 2016, 1 ноябрь, басылып чыгу номеры: 0001201611010013, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Мөмкинлекле тирәлек» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2019 елның 29 мартындагы 363 номерлы карары (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы, (www.pravo.gov.ru), 2019, 8 апрель, басылып чыгу номеры: 0001201904080016);

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Инвалидларны, сәламәтлеге буенча мөмкинлеге чикләнгән затларны һәм балигълык яшенә җитмәгәннәрне озата йөрүче» профессиональ стандартын раслау турында» 2015 елның 16 ноябрендәге 871н номерлы боерыгы (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2015, 18 декабрь, басылып чыгу номеры: 0001201512180009, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Мәшгульлек органнары һәм медик-социаль экспертиза буенча федераль учреждениеләр арасында белешмәләр алмашу тәртибен, формасын һәм срокларын раслау турында» 2015 елның 16 ноябрендәге 872н номерлы боерыгы (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2015, 14 декабрь,

басылып чыгу номеры: 0001201512140027, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып) (алга таба – 2015 елның 16 ноябрендәге 872н номерлы боерык);

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Медик-социаль экспертиза буенча дәүләт учреждениеләреннән бирелә торган инвалидны тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең хосусый программасын, инвалид баланы тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең хосусый программасын эшләү һәм гамәлгә ашыру тәртибен һәм аларның формаларын раслау турында» 2017 елның 13 июнендәге 486н номерлы боерыгы (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2017, 1 август, басылып чыгу номеры: 0001201708010058, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Халыкны эшкә урнаштыруга булышлык күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре алучының шәхси эш бланклары формаларын раслау турында» 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы боерыгы (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2019, 19 март, басылып чыгу номеры: 0001201903190024) (алга таба – 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерык);

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданнарга туры килә торган эш, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләр сайлауда булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәтенең федераль дәүләт стандартын раслау турында» 2012 елның 13 ноябрендәге 524н номерлы боерыгы белән расланган Гражданнарга туры килә торган эш, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләр сайлауда булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәтенең федераль дәүләт стандарты (Российская газета, 2013, 30 гыйнвар, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып) (алга таба – 2012 елның 13 ноябрендәге 524н номерлы Федераль стандарт);

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2018 елның 3 августындагы 518н номерлы боерыгы белән расланган Инвалидларга эшкә урнашуда булышлык күрсәткәндә озата йөрүне оештыру буенча дәүләт хезмәтенең федераль дәүләт стандарты (Хокукый мәгълүматның рәсми порталы (www.pravo.gov.ru), 2018, 22 август, басылып чыгу номеры: 0001201808220025) (алга таба – 518н номерлы Федераль стандарт);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре» 2007 елның 15 августындагы 388 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2007, № 33, 1178 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм

республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2010, № 46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып) (алга таба – 880 номерлы ТР МК карары белән расланган Тәртип).»;

1.9 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гариза формасы Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерыгы белән расланды.»;

2 бүлектә:

2.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама | Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе булып инвалидка инвалидларны эшкә урнаштыруда булышлык күрсәткәндә озата йөрүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында бәяләмә (алга таба – бәяләмә) бирү тора.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе инвалидның ихтыяры буенча кәгазьдәге документ формасында да, шулай ук әлеге Регламент нигезендә вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында да бирелергә мөмкин. | 518н номерлы Федераль стандартның 16 п., 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерыкка 25 нче кушымта; |

2.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «2.5. Закон яисә бүтән норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен, шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | Дәүләт хезмәтен алу өчен дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза).<br>Дәүләт хезмәте алу буенча гариза кәгазен гражданин халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин.<br>Бланкның электрон формасы халыкның мәшгульлек үзәге рәсми сайтында, Татарстан Республикасының Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталында урнаштырылган.<br>Гаризада түбәндәгеләр күрсәтелгән булырга тиеш:<br>инвалидның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта);<br>мөрәҗәгать итү датасы.<br><br>Гариза инвалидның шәхси яки 63-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә гади электрон имзасы белән таныклана.<br><br>Инвалид өчен гариза бирү ысулын сайлау мөмкинлеге тудырыла.<br>Гариза халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә яки КФҮ, почта элемтәсе ярдәмендә, факсимиль элемтә чараларыннан файдаланып яки электрон формада, шул исәптән халыкның мәшгульлек үзәгенең рәсми сайтыннан, Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм | 518н номерлы Федераль стандартның 5 п., 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерыкка 13 нче кушымта<br><br>518н номерлы Федераль стандартның 5 п.; 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерыкка 13 нче кушымта<br>63-ФЗ номерлы федераль закон, 210-ФЗ номерлы федераль закон, 518н номерлы Федераль стандартның 5 п.<br><br>518н номерлы Федераль стандартның 6 п. |

| | | |
|---|---|---|
| | муниципаль хезмәтләр порталыннан, Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнң (функцияләрнең) бердәм порталыннан яки «Инвалидларның федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасында «шәхси кабинет» аша (алга таба - «Инвалидларның федераль реестры» системасында «шәхси кабинет») аша тапшырылырга мөмкин. | |
| | Шәхсән мөрәҗәгать иткәндә инвалид Россия Федерациясе гражданины паспортын яки аны алмаштыра торган документны; чит ил гражданинының, гражданлыгы булмаган затның шәхесен таныклаучы документны күрсәтә | 518н номерлы Федераль стандартның 13 п. 4 абзацы; |

2.6 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасының сигезенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«документларның гамәлдә булу срогы бетү яки дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканнан соң мәгълүмат үзгәрү; дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда халыкның мәшгульлек үзәге хезмәткәренең хаталанып яки хокукка каршы килә торган гамәл кылуының (гамәл кылмавының) документаль расланган факты (билгеләре) ачыклану, бу хакта хаталанып яки хокукка каршы килә торган гамәл кылу (гамәл кылмау) факты ачыкланган көннән башлап эш көннәрендә исәпләнүче ун көнлек срокта язмача рәвештә, дәүләт хезмәтен күрсәтүче халыкның мәшгульлек үзәге җитәкчесе имзасы белән гражданинга хәбәр ителә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә»;

2.15 пунктта «Хезмәтне яки таләпне билгели торган норматив акт» графасында «880 номерлы ТР МК карарының 2.4 п.» сүзләрен «ТР МК 880 номерлы карары белән расланган Тәртипнең 2.4 п.» сүзләренә алмаштырырга;

3 бүлектә:

3.1.1 пунктта:

4 һәм 5 пунктчаларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) инвалидны эшкә урнаштыруда булышлык күрсәткәндә озата йөрү өчен ХМҮ җаваплы белгечен билгеләү яки оешма сайлау;

5) инвалидны эшкә урнаштыруда булышлык күрсәткәндә озата йөрү өчен җаваплы булган ХМҮ белгечен билгеләү турында боерык рәсмиләштерү, яисә инвалидка озата йөрү рәвешендә хосусый ярдәм күрсәтүне гамәлгә ашыручы дәүләткә карамаган оешма белән озата йөрү турында шартнамә төзү;»;

унынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документта җибәрелгән хаталарны төзәтү;»;

3.4 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«инвалидны эшкә урнаштыруда булышлык күрсәткәндә озата йөрү өчен җаваплы булган ХМҮ белгече билгеләнгәннән соң яки озата йөрүне гамәлгә ашыручы оешма белән шартнамә төзелгәннән соң ХМҮ белгече дәүләт хезмәте

күрсәтү турында бәяләмә рәсмиләштерә, анда 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерыкка 25 нче кушымтага туры китерелгән форма буенча озата йөрү өчен билгеләнгән затлар (оешмалар) турында мәгълүмат була һәм аны инвалидка тапшыра.»;

3.5 пунктның беренче абзацында «Озата йөрү өчен җаваплы булган халыкның мәшгульлек үзәге хезмәткәрен билгеләү» сүзләрен «Инвалидны эшкә урнаштыруда булышлык күрсәткәндә озата йөрү өчен җаваплы булган халыкның мәшгульлек үзәге хезмәткәрен билгеләү» сүзләренә алмаштырырга;

3.6 пунктның беренче абзацында «Инвалидны турыдан-туры озата йөрү белән шөгыльләнүче халыкның мәшгульлек үзәгенең җаваплы хезмәткәрен билгеләү турында боерык рәсмиләштерү» сүзләрен «Инвалидны эшкә урнаштыруда булышлык күрсәткәндә озата йөрү өчен җаваплы булган үзәк белгечен билгеләү турында боерык рәсмиләштерү» сүзләренә алмаштырырга;

3.6.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6.1. ХМҮ белгече 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерыкка 24 нче кушымтага туры китерелгән форма буенча инвалидны эшкә урнаштыруда булышлык күрсәткәндә озата йөрү өчен җаваплы булган ХМҮ белгечен билгеләү турында боерык рәсмиләштерә һәм имзалау өчен халыкның мәшгульлек үзәге директорына боерыкны тапшыра. Халыкның мәшгульлек үзәге директоры боерыкка кул куя һәм аны ХМҮ белгеченә кайтарып бирә.

Инвалидны эшкә урнаштыруда булышлык күрсәткәндә озата йөрү өчен җаваплы булган ХМҮ белгече боерык белән кул куеп таныша.»;

3.6.2 пунктның унөченче абзацында «инвалидны эшкә урнаштыруда булышлык күрсәткәндә озата йөрү өчен ХМҮ белгечен билгеләү турында боерык,» сүзләрен «инвалидны эшкә урнаштыруда булышлык күрсәткәндә озата йөрү өчен җаваплы булган ХМҮ белгечен билгеләү турында боерык» сүзләренә алмаштырырга;

3.7 пунктта:

икенче абзацта «инвалидны эшкә урнаштыруда булышлык күрсәткәндә озата йөрү өчен ХМҮ белгечен билгеләү турында боерык,» сүзләрен «инвалидны эшкә урнаштыруда булышлык күрсәткәндә озата йөрү өчен җаваплы булган ХМҮ белгечен билгеләү турында боерык» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «әлеге Регламентка 4 нче кушымтага туры китерелгән форма буенча бәяләмә» сүзләрен «2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерыкка туры китерелгән форма буенча бәяләмә» сүзләренә алмаштырырга;

5 бүлектә:

5.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр судка кадәр тәртиптә халыкның мәшгульлек үзәгенең дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы белгечләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата халыкның мәшгульлек үзәге җитәкчесенә дәгъва белдерү хокукына ия.

Халыкның мәшгульлек үзәге җитәкчесе карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр Министрлыкка министр исеменә тапшырыла.

Министр карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына шикаять белдерелергә мөмкин.

КФҮ хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр КФҮ җитәкчесенә белдерелә, КФҮ җитәкчесе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата – КФҮ гамәлгә куючыга.»;

5.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле кызыл юл өстәргә:

«КФҮ, КФҮ хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять почтадан, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, КФҮ (http://mfc16.tatarstan.ru) рәсми сайтыннан, Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru), Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (https://www.gosuslugi.ru) җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә алынырга мөмкин.»;

Регламентка 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Инвалидларга эшкә урнашуда
булышлык күрсәткәндә озата
йөрүне оештыру буенча дәүләт
хезмәте күрсәтүнең административ
регламентына 1 нче кушымта

1. Татарстан Республикасы халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләре

| Халыкның мәшгульлек үзәге аталышы | Телефон | Урнашкан урын адресы, электрон адресы |
|---|---|---|
| Әгерҗе районы буенча «Менделеевск районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ филиалы | (85551) 2-31-73 | 422230, Әгерҗе ш., К.Маркс ур., 11а. Centr.Agryzskiy@tatar.ru |
| «Азнакай шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (85592) 7-57-90 | 423330, Азнакай ш., Төзүчеләр ур., 10. Czn.Aznakaevo@tatar.ru |
| «Аксубай районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (84344) 2-73-94 | 423060, Аксубай ш.т.п., Романов ур., 6 Czn.Aksubaevo@tatar.ru |
| «Актаныш районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (85552) 3-09-83 | 423740, Актаныш ав., Ленин пр., 8 Czn.Aktanysh@tatar.ru |
| «Алексеевск районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (84341) 2-54-00 | 422900, Алексеевск э.п., Ленин ур., 87 Czn.Alekseevskoe@tatar.ru |
| «Әлки районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (84346) 2-15-89 | 422870, Базарлы Матак ав., Совет ур., 8 й. Czn.Alkeevo@tatar.ru |
| «Әлмәт шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (8553) 32-34-99 | 423452, Әлмәт ш., Герцен ур., 86а |

| | | |
|---|---|---|
| | | Czn.Almet@tatar.ru |
| «Апас районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (84376) 2-12-15 | 422350, Апас ав.,<br>Шоссе ур., 5<br>Czn.Apastovo@tatar.ru |
| «Арча районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (84366) 3-17-33 | 422000, Арча ш.т.п., Банк ур., 6в<br>Centr.Arskiy@tatar.ru |
| «Әтнә районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (84369) 2-16-51 | 422750, Олы Әтнә ав.,<br>Совет ур., 63<br>Czn.Atnya@tatar.ru |
| «Баулы шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (85569) 5-62-29 | 423930, Баулы ш., Энгельс ур., 56<br>Czn.Bavly@tatar.ru |
| «Балтач районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (84368) 2-44-19 | 422250, Балтач ш.т.п.,<br>Совет ур., 16<br>Czn.Baltasi@tatar.ru |
| «Бөгелмә шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (85594) 4-17-60 | 423230, Бөгелмә ш.,<br>Октябрь ур., 15<br>Czn.Bugulma@tatar.ru |
| «Буа шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (84374) 3-13-73 | 422430, Буа ш.,<br>Р.Люксембург ур., 157/1<br>Czn.Buinsk@tatar.ru |
| «Югары Ослан районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (84379) 2-18-99 | 422570, Югары Ослан ав.,<br>Медгородок ур., 1<br>Czn.V-uslon@tatar.ru |
| «Биектау районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (84365) 3-16-17 | 422700, Биек Тау ав.,<br>Үзәк ур., 7<br>CZN.VGora@tatar.ru |
| «Чүпрәле районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (84375) 2-25-87 | 422470, Иске Чүпрәле ав.,<br>Үзәк ур., 15<br>Czn.Drozhzhanoe@tatar.ru |
| «Алабуга шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (85557) 7-58-58 | 423600, Алабуга ш., Спас ур., 5<br>Czn.Elabugi@tatar.ru |
| «Зәй шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (85558) 7-15-43 | 423520, Зәй ш., Нефтьчеләр пр., 37б<br>Czn.Zainsk@tatar.ru |
| «Яшел Үзән шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (84371) 5-64-90 | 422550, Яшел Үзән ш.,<br>Татарстан ур., 1<br>Czn.Zdol@tatar.ru |
| «Кайбыч районы халыкның | (84370) 2-12-60 | 422330, Олы Кайбыч ав., |

| | | |
|---|---|---|
| мәшгульлек үзәге» ДКУ | | Кояшлы бульвар, 7<br>Czn.Kaibicy@tatar.ru |
| Кама Тамагы районы буенча «Тәтеш районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ филиалы | (84377) 2-14-67 | 422820, Кама Тамагы ш.т.п., К.Маркс ур., 2<br>Filial.K-uste@tatar.ru |
| «Кукмара районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (84364)<br>2-67-54 | 422110, Кукмара ш., Ворошилов ур.,44<br>Czn.Kukmor@tatar.ru |
| «Лаеш районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (84378)<br>2-48-12 | 422610, Лаеш ш., Беренче май ур., 35.<br>Laish.Czn@tatar.ru |
| «Лениногорск шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (85595) 5-59-70 | 423250, Лениногорск ш., Гагарин ур., 51<br>Czn.Leninogorsk@tatar.ru |
| «Мамадыш районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (85563) 3-35-57 | 422190, Мамадыш ш., Карл Маркс ур., 14<br>Czn.Mamadysh@tatar.ru |
| «Менделеев районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (85549) 2-23-57 | 423650, Менделеев ш., Фомин ур., 19<br>Czn.Men@tatar.ru |
| «Минзәлә районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (85555) 3-23-80 | 423700, Минзәлә ш., Ленин ур., 80<br>Czn.Menzelinsk@tatar.ru |
| «Мөслим районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (85556) 2-55-80 | 423970, Мөслим ав., Пушкин ур., 47<br>Czn.Muslymovo@tatar.ru |
| «Яр Чаллы шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (8552) 52-42-68 | 423831, Яр Чаллы ш, Сөембикә пр., 47<br>Chelny.CZn@tatar.ru |
| «Түбән Кама шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (8555) 42-40-79 | 423570, Түбән Кама ш., Бызов урамы, 20а<br>Czn.Nk@tatar.ru |
| «Түбән Кама шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ Кама Аланы бүлеге | (8555) 33-98-61 | 423564, Түбән Кама районы, Кама Аланы э.п., 2/01<br>Czn.Nk@tatar.ru |
| «Яңа Чишмә районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (84348) 2-30-42 | 423190, Яңа Чишмә ав., Совет ур., 80 й.<br>Czn.Novoshesh@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| «Нурлат шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (84345) 2-46-30 | 423040, Нурлат ш.,<br>Р.С.Хәммәдиев урамы, 19<br>Czn.Nurlat@tatar.ru |
| «Питрәч районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (84367) 3-04-84 | 422770, Питрәч ав.,<br>Совет ур., 20 й.<br>CentrZan.Pestr@tatar.ru |
| «Балык Бистәсе районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (84361) 2-21-81 | 422650, Балык Бистәсе ш.т.п.,<br>Ленин ур., 48 й.<br>Czn.R.sloboda@tatar.ru |
| «Саба районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (84362) 2-28-15 | 422060, Байлар Сабасы ш.т.п.,<br>З.Йосыпов ур., 7 й.<br>SZN.Saby@tatar.ru |
| «Сарман районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (85559) 2-42-62 | 423350, Сарман ав.,<br>Ленин ур., 26<br>Czn.Sarmanovo@tatar.ru |
| «Спас районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (84347) 3-07-72 | 422820, Болгар ш.,<br>Хирург Шеронов ур., 21<br>Czn.Bolgar@tatar.ru |
| «Тәтеш районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (84373) 2-63-29 | 422370, Тәтеш ш.,<br>Ирек мәйданы ур., 45<br>Czn.Tetyushi@tatar.ru |
| Тукай районы буенча «Яр Чаллы шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ филиалы | (8552) 52-96-97 | 423831, Яр Чаллы ш.,<br>Сөембикә пр., 47<br>Czn.Tukaev@tatar.ru |
| «Теләче районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (84360) 2-13-51 | 422080, Теләче ав.,<br>Ленин ур., 73 й.<br>Czn.Tyulyachi@tatar.ru |
| «Чирмешән районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (84396) 2-54-59 | 423100, Чирмешән ав.,<br>Титов ур., 5 й.<br>Czn.Cheremshan@tatar.ru |
| «Чистай шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (84342) 5-13-34 | 422980, Чистай ш.,<br>К.Маркс ур., 35 й.<br>Czn.chist@tatar.ru |
| «Ютазы районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (85593) 2-98-00 | 423950, Урыссу ш.т.п.,<br>Пушкин ур., 38 й.<br>Czn.Yutazy@tatar.ru |
| «Казан шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (843) 562-48-33 | 420034, Казан ш.,<br>Декабристлар урамы, 81а<br>Czn.g_Kazan@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| Совет районы буенча «Казан шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ филиалы | (843) 273-85-03 | 420029, Казан ш.,<br>Журналистлар урамы, 13а<br>CZN/Sovetskiy@tatar.ru |
| «Авиатөзелеш районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (843) 537-86-00 | 420085, Казан ш.,<br>1 нче Муром урамы, 33 а<br>Czn.Avia@tatar.ru |
| «Вахитов районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (843) 277-40-09 | 420049, Казан ш.,<br>Качалов урамы, 77<br>Czn.Vah@tatar.ru |
| «Киров районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (843) 554-77-36 | 420032, Казан ш.,<br>Слободская урамы, 23<br>czn.kirovskiy@tatar.ru |
| «Мәскәү районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (843) 564-58-72 | 420039, Казан ш.,<br>Гагарин ур., 46 й.<br>czn.moskovski@tatar.ru |
| «Яңа Савин районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (843) 560-88-98 | 420044, Казан ш.,<br>Ибраһимов пр., 41<br>Czn.Novosavin@tatar.ru |
| «Идел буе районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (843) 224-86-83 | 420101, Казан ш.,<br>Бертуган Касыймовлар урамы, 22/7<br>CZN.Privol@tatar.ru». |

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы

| Вазыйфа атылышы | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | 557-20-01 | mtsz@tatar.ru |
| Министр урынбасары | 557-20-03 | mtsz@tatar.ru |
| Социаль яклнанмаган категорияләр өчен эш урыннары булдыру бүлеге башлыгы | 557-20-73 | Elena.Kibardina@tatar.ru |

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты

| Вазыйфасы | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш | 264-77-29 | pisma@tatar.ru» |

| | | |
|---|---|---|
| идарәсе башлыгы | | |

Регламентка 2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Инвалидларга эшкә урнашуда булышлык күрсәткәндә озата йөрүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

## Инвалидларга эшкә урнашуда булышлык күрсәткәндә озата йөрүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең БЛОК-СХЕМАСЫ

Дәүләт хезмәтен күрсәтә башлау нигезе булып түбәндәгеләр тора:

1) инвалидның яки мөрәҗәгать итүченең гариза белән халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән мөрәҗәгать итүе;

Инвалид шәхсән мөрәҗәгать иткәндә мәшгульлек үзәгенә килгән гариза ХМҮ белгече тарафыннан инвалид шәхсән мөрәҗәгать иткән көнне халыкның мәшгульлеге өлкәсендә дәүләт хезмәте алучылар регистрын үз эченә алучы ПКда теркәлә.

2) инвалидның халыкның мәшгульлек үзәгенә, гаризаны почта элемтәсе ярдәмендә, факсимиль элемтә чараларыннан файдаланып яки электрон формада, шул исәптән халыкның мәшгульлек үзәге рәсми сайтыннан, Татарстан Республикасы Порталыннан, Бердәм порталдан файдаланып яки «Инвалидларның федераль реестры» системасындагы «шәхси кабинет», КФҮ аша җибәргән очракта, алдан ук аның белән килешенгән датада һәм вакытта мөрәҗәгать итүе.

Инвалид яки мөрәҗәгать итүче гаризаны почта элемтәсе белән, электрон формада, шул исәптән халыкның мәшгульлек үзәге рәсми сайты, Татарстан Республикасы Порталы, Бердәм портал яки «Инвалидларның федераль реестры» системасында «шәхси кабинет» аша җибәрелгән очракта, ХМҮ белгече гаризаны кәгазьдә чыгартып ала һәм килгән көнендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү турында гаризаларны теркәү журналында терки.

Гаризаны КФҮ тапшырганда, гариза ул килгән көнне КФҮ хезмәткәре тарафыннан теркәлә. КФҮ белән халыкның мәшгульлек үзәге арасында төзелгән хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән срокларда, ләкин гаризаны теркәгән көннән башлап киләсе эш көненнән соңга калмыйча, гаризаның халыкның мәшгульлек үзәгенә тапшырылуы тәэмин ителә. Гариза халыкның мәшгульлек үзәгенә КФҮ килгән очракта, гариза ул КФҮ килгән көнне ХМҮ белгече тарафыннан ПК теркәлә

↓

ХМҮ белгече әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган, тапшырылган документлар нигезендә инвалид турындагы белешмәләрне анализлый, ТАХПда һәм мөрәҗәгать итүчегә тәкъдим ителә торган вакансияләрдә хезмәт холкына һәм шартларына анализ нәтиҗәләре буенча бирелгән эшкә урнашуда булышлык күрсәтелгәндә инвалидның озата йөрүгә мохтаҗ булуы турында МСЭ күрсәтмәсендә белешмәләр (инвалидның яшәешендә булган чикләмәләр турында, күрсәтелгән яки күрсәтелмәгән хезмәт эшчәнлеге төрләре, киңәш ителә торган хезмәт шартлары турында) булуын исәпкә ала. Административ гамәлләрне башкаруның максималь срогы инвалид халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә 5 минуттан артып китәргә тиеш түгел

⇄

Инвалид ТАХП тапшырмаган очракта, ХМҮ белгече МСЭ белән мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында ТАХП өземтә сората һәм, организмының бозылган функцияләрен һәм яшәешендәге чикләмәләрне исәпкә алып, инвалидка киңәш ителә торган хезмәт һәм һөнәри эшчәнлек төрләрен сайлау өчен белешмәләрне электрон формада ала. МСЭ биргән ТАХП инвалид тарафыннан шәхси ихтыяры белән тапшырылмаган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь мөмкин булган вакыты мөрәҗәгать итүче гариза тапшырган датадан башлап 7 эш көненнән артык булырга тиеш түгел

↓

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар

ХМҮ белгече инвалидка дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат бирә.
Административ гамәлләрне үтәүнең максималь срогы инвалидка дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар кабул ителгән вакыттан башлап 3 минуттан артып китәргә тиеш түгел

ХМҮ белгече килгән документларны карый, инвалидны эшкә урнаштыруда булышлык күрсәткәндә озата йөрү өчен җаваплы ХМҮ белгечен билгеләү турында карар кабул итә.
Дәүләт хезмәтен халыкның мәшгульлек үзәгендә күрсәтү мөмкин булмаган очракта, ХМҮ белгече дәүләткә карамаган оешманы җәлеп итү турында карар кабул итә.
Административ гамәлләрне үтәүнең максималь срогы инвалидка дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат җиткерелгән вакыттан башлап 5 минуттан артып китәргә тиеш түгел

ХМҮ белгече инвалидка озата йөрү рәвешендә ярдәм күрсәтү турында шартнамә төзү максатында дәүләткә карамаган оешма турында мәгълүмат җыюны һәм анализлауны гамәлгә ашыра. Дәүләткә карамаган оешмалар турында мәгълүматны анализлау нәтиҗәләре буенча мәшгульлек үзәге белгече шартнамә төзү мөмкинлеге булган дәүләткә карамаган оешмалар исемлеген формалаштыра.
Административ гамәлләрне үтәүнең максималь срогы инвалидка дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат җиткерелгән вакыттан башлап 5 минуттан артып китәргә тиеш түгел

ХМҮ белгече шартнамә проектын әзерли һәм дәүләткә карамаган оешма белән килештерә. Аны ике нөсхәдә бастырып чыгара һәм аларны кул кую өчен халыкның мәшгульлек үзәге директорына тапшыра.
Директор шартнамәнең ике нөсхәсен имзалый һәм аларны ХМҮ белгеченә тапшыра.
ХМҮ белгече халыкның мәшгульлек үзәге директоры тарафыннан имзаланган шартнамәнең ике нөсхәсенә мәшгульлек үзәге мөһере тамгасын куя һәм имзалау өчен дәүләткә карамаган оешмага җибәрә.
Административ гамәлләрне башкаруның максималь срогы озата йөрүче оешманы билгеләү вакытыннан башлап 34 минуттан артып китәргә тиеш түгел.
ХМҮ белгече ике нөсхәдә шартнамә проектын кул кую өчен оешмага җибәрә

Инвалидны эшкә урнаштыруда булышлык күрсәткәндә озата йөрү өчен җаваплы ХМҮ белгечен билгеләү турында боерык рәсмиләштерелә, бастырып чыгаручы җайланмадан ике нөсхәдә чыгартыла һәм имза салу өчен мәшгульлек үзәге директорына тапшырыла.
Административ гамәлләрне башкаруның максималь срогы озата йөрү өчен җаваплы ХМҮ белгече кандидатурасын билгеләгән яки озата йөрү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтәчәк оешманы сайлаган вакыттан башлап 34 минуттан артып китәргә тиеш түгел

Халыкның мәшгульлек үзәге белән оешма арасында шартнамә имзалау срогы шартнамә проекты төзелгән датадан башлап 2 эш көненнән артык булырга тиеш түгел.

ХМҮ белгече электрон рәвештә бәяләмә төзи, аны ике нөсхәдә чыгартып ала, имзалый. Бәяләмәдә озата йөрүне гамәлгә ашыручы ХМҮ белгече яки оешма турында мәгълүматлар чагылдырыла. Административ гамәлләрне башкаруның максималь срогы 5 минуттан артык булырга тиеш түгел.

ХМҮ белгече гаризада күрсәтелгән ысул белән инвалидка бәяләмә тапшыра. Инвалид халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, инвалидны бәяләмә белән кул куйдыртып таныштыра һәм инвалидка бер нөсхәсен бирә, икенче нөсхәсен инвалидның шәхси эшенә терки. Административ гамәлләрне башкаруның максималь срогы 5 минуттан артык булырга тиеш түгел.

ХМҮ белгече Халыкның мәшгульлеге өлкәсендә дәүләт хезмәтләрен алучылар регистрына дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәләре турында мәгълүматны кертә.
Административ гамәлләрне үтәүнең максималь срогы дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алган вакыттан башлап 1 минуттан артып китәргә тиеш түгел.

Регламентка 3 нче, 4 нче кушымталарны көчен югалткан дип танырга.